**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзәк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

**19 сентябрь 2019 ел** **№ 119**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Ульяновка авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Ульяновка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Ульяновка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендә кабул ителгән 118 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Шешминка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Сосновка, Девичья Поляна торак пунктларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту

һәм хезмәт күрсәтү, урам утларынын бишенче чыбыгын урнаштыру, кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Ульяновка, Нагорный, Саминовка, Наратлык, Девичья Поляна авылларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлауга, урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып алуга, хезмәт күрсәтүләргә чыгымнар) югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Ульяновка, Нагорный һәм Саминовка торак пунктларында су челтәрен реконструкцияләү, су башнялары, скважиналар территориясен төзекләндерү, кулланылган электр энергиясе һәм хезмәт күрсәтүләр өчен чыгымнарны түләү;

- «Сирена» тавышлы җайланманы сатып алу, урнаштыру, монтажлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

ӘЙЕ ЮК »

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» - («Наш Черемшан») район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе Шәмсетдинов С.З.